**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Кооперативная ур, 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**02.06.2022 ел** **№ 556**

**Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «2022-2024 елларга Биектау муниципаль районы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү» муниципаль максатчан программасын раслау турында» 2022 елның 04 апрелендәге 391 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Авыл хуҗалыгы җитештерүен үстерүгә муниципаль ярдәм итү, шул исәптән Биектау муниципаль районы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү, шәхси ярдәмче хуҗалыкларның тотрыклы эшләвен тәэмин итү һәм мөгезле эре терлекләрнең баш санын арттыру исәбенә аларның керемнәрен арттыру, базар икътисады һәм милек формаларының күптөрлелеге шартларында авыл халкының тормыш дәрәҗәсен күтәрү, шәхси ярдәмче хуҗалыклар ияләренең икътисади мәнфәгатьләрен яклау максатларында, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 04 апрелендәге 391 номерлы карарына түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

1.1. программа паспортындагы «Финанслау чыганаклары» бүлегенең 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr><td>Финанслау чыганаклары</td><td>Программаны финанслау күләме Биектау муниципаль районы бюджетының өстәмә керемнәре һәм (яисә) район бюджетының калган акчалары исәбеннән 9000,0 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:
<table>
<tr><td>2022 ел</td><td>3000,0 мең сум</td></tr>
<tr><td>2023 ел</td><td>3000,0 мең сум</td></tr>
<tr><td>2024 ел</td><td>3000,0 мең сум</td></tr>
</table>
Һәр программа буенча лимитны елына 1000,0 мең сум күләмендә расларга.<br>Искәрмә: финанслау күләмнәре фаразлау характерында һәм, Биектау муниципаль районы бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, төзәтмәләр кертелергә тиеш.</td></tr>
</table>

1.2. «Программаны гамәлгә ашыруның көтелә торган ахыргы нәтиҗәләре» бүлеген программа паспортында түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| **Программаны тормышка ашыруның көтелгән ахыргы нәтиҗәләре** | Программаны тормышка ашырудан социаль-икътисади нәтиҗәлелек түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>- шәхси ярдәмче хуҗалыкларда җитештерү эшчәнлеген үстерүдән;<br>- район авылларында яшәүчеләрнең нормаль көн күрүе өчен шартлар булдырудан;<br>- шәхси ярдәмче хуҗалыкларның (ШЯХ) тотрыклы эшләвен тәэмин итүдән;<br>- 2022 елда субсидияләр рәвешендә ярдәм алган гражданнарга эре мөгезле терлекләрнең баш санын арттыру исәбенә керемнәрне кимендә 5%ка арттыруда;<br>- базар икътисады һәм милек формаларының күптөрлелеге шартларында авыл халкының тормыш-көнкүреш дәрәҗәсен күтәрүдә;<br>- шәхси ярдәмче хуҗалыклар ияләренең (физик затларның) икътисади мәнфәгатьләрен яклаудан. |

1.3. 5.1. бүлектә:

1.3.1. 2 абзацта «Гариза авыл җирлекләре башлыкларына ел саен 01 сентябрьгә кадәр бирелә» җөмләсен «Гариза Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлегенә 01 июльдән 01 сентябрьгә кадәр бирелә» җөмләсенә алыштырырга.

1.3.2. 3 абзацны үз көчен югалткан дип санарга, чөнки авыл җирлеген фактта сайлау каралмаган.

1.3.3. 4 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Программаның нәтиҗәлелеген арттыру өчен, Биектау муниципаль районының барлык авыл җирлекләре сайлап алуда катнаша».

1.3.4. 5 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Финанс ярдәме алырга теләүче ШЯХ гражданнарына Биектау муниципаль районы башкарма комитетының икътисад бүлегенә гариза бирергә кирәк. Гариза нигезендә Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге һәр программа буенча, 2 нче кушымта нигезендә форма буенча, финанс ярдәменең белешмә-хисабын әзерли. Белешмә-хисап районның Финанс-бюджет палатасына тапшырыла».

1.3.5. 6 абзацка өстәргә:

-шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы һәм алты һәм аннан күбрәк савым сыеры булган гражданнарга саву аппараты сатып алуга - 30 000 сум;

- товарлыклы таналар һәм (яисә) беренче мәртәбә бозаулаган таналар сатып алуга (милектә 2 һәм аннан да күбрәк сыер булса, яңа сатып алганнардан тыш) - 30 000 сум;

- нәселле таналар һәм (яисә) беренче мәртәбә бозаулаган таналар сатып алуга

(милектә 2 һәм аннан да күбрәк сыер булса, яңа сатып алганнардан тыш) - 40 000 сум.

2. Әлеге карарны интернет челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ урнаштырып игълан итәргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Ф.Хисамутдинов